СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ 25.10.2018

КАРАР № 63-270

с. Набережные Моркваши

Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 26 нчы апрелендә кабул ителгән 51-215 нче номерлы «Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында" ТР МКның 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы карарына таянып, Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставы нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. “Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең 2018 елның 26 апрелендәге 51-215 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 п. икенче абзацта «4.65» санын «6,72» саннарына алмаштырырга;

2. Әлеге карар 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, әһәмияте һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы ____________________ И.Х.Гаязов